ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2019 Казан шәһәре № 5-107/тэ

«РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте күрсәтә торган җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә 2020 елга тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «РСК» ҖЧҖ) тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә, шушы карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис в.б. Л.П. Борисова

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 11.12.2019
№ 5-107/тэ карарына кушымта

«РСК» ЖЧЖ тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә 2020 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

<table>
<tr><th rowspan="2">т/с</th><th rowspan="2">Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы</th><th rowspan="2">Тариф төре</th><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="2">Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре</th></tr>
<tr><th>су</th><th>пар</th></tr>
<tr><td></td><td colspan="5">Казан шәһәре</td></tr>
<tr><td rowspan="3">1</td><td rowspan="3">«РСК» ЖЧЖ Казан шәһәренең ЕТО-3 гамәлдә булу зонасында</td><td colspan="4">Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Бер ставкалы, сум/Гкал</td><td>01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр</td><td>284,25</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр</td><td>295,75</td><td>-</td></tr>
</table>

<*> - Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2018 елның 16 августындагы 658 номерлы боерыгы белән расланган Казан шәһәренең җылылык белән тәэмин итү схемасына нигезләнеп билгеләнде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге